**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,
Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**КУТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Кутәмә авылы,
Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396)
4-30-88
email:Kut.Cmn2@tatar.ru

№ 86 14 май 2018 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 мартындагы 80 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы», 2018 елның 22 мартындагы 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасының Законнары, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, район прокурорының 2018 елның 13 апрелендәге 02-01-19/345-р номерлы «Муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» тәкъдимен карап тикшергәннән соң, Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 мартындагы 80 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне кертергә:

- 2.3.3. бүлекнең 1 пунктын бәян итәргә: 1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: югары һөнәри белем булу, - вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары һәм урта һөнәри белем булу, - вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

- 2.3.3 бүлегендәге 9 абзацта «тиешле вазыйфаи төркемнәр» сүзтезмәсен төшереп калдырырга;

- 4.1.3. бүлек:

- 8 пунктчада «хәрби бурычлылар өчен» сүзтезмәсен «запаста торучы гражданнар өчен» дип бәян итәргә;

- 9 пунктчада «учреждение» сүзен «оешма» дип бәян итәргә;

- 4.3.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфасына туры килүе яки туры килмәве турында карар чыгара. Аттестация комиссиясе аерым муниципаль хезмәткәрләрне үз эшләрендә ирешкән уңышлары өчен бүләкләү турында, шул исәптән аларны вазыйфаларында арттыру турында, ә кирәкле очракта аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр бирергә мөмкин. Аттестация нәтиҗәләре аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгарганнан соң ук хәбәр ителә. Аттестация материаллары яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла;

- 6.4 бүлегендәге 4 абзацны яңа редакцияда бәян итәргә «Муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия муниципаль хезмәт стажы булганда, аның озынлыгы тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс нигезендә билгеләнә һәм муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кеременең 20 проценты күләмендә билгеләнә. Муниципаль хезмәт стажының һәр тулы елы өчен күрсәтелгән стаждан тыш тиешле еллар эшләгән өчен пенсия айлык акчалата керемнең 3 процентына арта. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кеременең 50 процентыннан артмаска тиеш»;

- 6.4. бүлектә:

- 1.2. өлешне бәян итәргә «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәттән киткәндә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты белән (закон көченә кергән суд карары белән муниципаль хезмәткәрне хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип таныган очракта), Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясының беренче өлешенең 2 пункты (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләренең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы чыгу очракларыннан тыш), 5 (дәүләт хезмәтенә күчерелгән яки сайлау эшенә (вазыйфага) күчкән очракта), 8 һәм 9 пунктлары, 81 статьяның беренче өлешендәге 1 һәм 2 пунктлары, 83 статьяның беренче өлешендәге 2, 5 һәм 7 пунктлары белән каралган нигезләр буенча, эштән азат ителгән вакытка картлык

(инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә хокук алуга бәйсез рәвештә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алырга хокуклы»;

- 2 өлешне бәян итәргә «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәттән киткәндә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешнең 1, 2 пунктлары (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләренең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы чыгу очракларыннан тыш), 3 һәм 7 пунктлары, 81 статьяның беренче өлешендәге 3 пунктында каралган нигезләр буенча, «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәнче, йә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясен яки инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләү, әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 2 өлешенең 3 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән вазыйфаларда, шулай ук әлеге статьяның 2.1 өлеше нигезендә башка вазыйфаларда 15 елдан да ким булмаган эш (хезмәт) стажы булган очракта тиешле елларны эшләгән өчен пенсия алырга хокуклы»;

- 6.4.1 пунктының 1 пунктчасы. яңа редакциядә бәян итәргә: «тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен аның озынлыгы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс нигезләмәләре нигезендә билгеләнә торган муниципаль хезмәт стажы булу»;

6.4.1 пунктының 1 пунктчасы. яңа редакциядә бәян итәргә: «тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен аның озынлыгы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс нигезләмәләре нигезендә билгеләнә торган муниципаль хезмәт стажы булу"»;

- 6.4.3 пунктының 1 абзацы «хезмәт» сүзен «иминият» сүзенә алмаштырырга;

- 6.4.4 пункт. яңа редакциядә бәян итәргә «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия исәпләнә һәм билгеләнә торган айлык акчалата керем составына вазыйфаи оклад һәм сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә кертелә»;

6.4.4 пункт. яңа редакциядә бәян итәргә «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия исәпләнә һәм билгеләнә торган айлык акчалата керем составына вазыйфаи оклад һәм сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә кертелә»;

- 6.4.6 пунктының 1 абзацы «яшәү урыны» дигән сүзтезмәне - төшереп калдырырга;

- 6.4.13 пунктта «хезмәт» сүзен «иминият» сүзенә алмаштырырга;

- 6.5.2 бүлегендәге 4 пунктының «в» пунктчасы «Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

- 6.5.2 бүлегендәге 3 пунктының «г» пунктчасы «Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе А.Н. Абрськина